**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Ютазы мунципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Ак-Чишмә торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**22.11.2023 ел** **№ 6**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Ак-Чишмә торак пунктында узган гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, Украинада махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның якын туганнарыннан (әти-әниләре, тормыш иптәшләре, балигъ булган балалары), Украинада махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның якын туганнарыннан (әти-әниләре, тормыш иптәшләре, балигъ булган балалары), 1 группа инвалидлардан тыш, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Ак-Чишмә торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Ак-Чишмә торак пунктында Бөек Ватан сугышында катнашучылар истәлегенә мемориаль такта урнаштыру (проект төзү, проект төзү хезмәте күрсәтү, төзелеш материаллары һәм җиһазлары сатып алу, нигез салу җайланмасы, мемориал сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев